Важашур авыл җирлеге Советы

КАРАР

№12

22 март, 2024 ел

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Иске Каенсар авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Иске Каенсар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы Иске Каенсар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Важашур авыл җирлеге Уставы нигезендә, Важашур авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 04 апреленә 09 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Иске Каенсар торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Иске Каенсар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Иске Каенсар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге Иске Каенсар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Иске Каенсар авылының Тынычлык, Яшел урамнарында, вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау. проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Иске Каенсар авылында Тынычлык урамына елга аша чыгу юлын ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Иске Каенсар авылындагы юлны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту, проект-смета документлары;
- Иске Каенсар авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу, проект-смета документлары;
- Иске Каенсар авылындагы Яшел урамыннан Тынычлык урамына елга аша җәяүлеләр күперен ремонтлау, проект-смета документлары;

- Иске Каенсар авылында янгын краны сатып алу һәм урнаштыру проект-смета документлары?

2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту *(Иске Каенсар авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);*

*(юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре),*

*(Иске Каенсар авылында Тынычлык урамына елга аша чыгу юлын ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм башка эш төрләре);*

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау *(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу, Иске Каенсар авылында урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре*);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау *(Иске Каенсар авылындагы Яшел урамыннан Тынычлык урамына елга аша җәяүлеләр күперен ремонтлау, проект-смета документлары, башка эш төрләре);*

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү - *Иске Каенсар авылында янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, янгынга каршы инвентарь сатып алу, проект-смета документлары).*

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л. Иванов

ОГРН 1021607752770
ИНН 1623001134